Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Тубән Кәчи җирлеге башкарма комитеты Карары

2014 елның 28 феврале 7№

Җирлек территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи җирлегенең торак пунктлары территорияләрен ташландык, хуҗасыз транспорт чараларыннан азат итү, транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтенә каршылык булдырмау, торак пунктларда һәм алардан читтә экологик вәзгыятьне тотрыкландыру, мондый транспорт чараларын хокукка каршы максатларда файдалану мөмкинлегенә бәйле хокук бозуларны профилактикалау эшләрен оештыру максатларында Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Тубән Кәчи җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи җирлеге территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әлки муниципаль районы Тубән Кәчи җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе М.И.Елифанов

Әлки муниципаль районы Түбән
Кәчи жирлеге башкарма
комитетының 2014.28.02, 7№
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районынын Тубән Кәчи жирлеге территориясендә ташландык, хужасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге үрнәк тәртип (алга таба-тәртип) гомуми файдаланудагы урыннарда (йорт яны территорияләрендә) булган ташландык, хужасыз, юл йөрү, җәяүлеләр үтүгә, территорияне җыештыруга, махсус транспорт һәм чүп-чар җыю машиналарының подъездларга һәм чүп-чар контейнерларына керүенә комачаулаучы һәм (яки) Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Тубән Кәчи жирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозып урнаштырылган (алга таба – төзекләндерү кагыйдәләре) транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, махсуслаштырылган автостоянкаларга саклау, утильләштерү эшләрен оештыру процедурасын регламентлый.

## II. Төп төшенчәләр

Әлеге Тәртип максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

транспорт чарасы - юлларда кешеләр, йөкләр яисә анда урнаштырылган җиһазлар (шул исәптән прицеплар, ярымприцеплар һәм транспорт чарасы белән составта хәрәкәт итү өчен билгеләнгән башка җайланмалар) йөртү өчен билгеләнгән җайланма;

хуҗасыз транспорт чарасы - милекчесе булмаган яисә милекчесе билгеле булмаган яки, әгәр башка законнарда каралмаган булса, милек хокукыннан баш тарткан транспорт чарасы;

ташланган транспорт чарасы - милекче тарафыннан 6 ай һәм аннан да күбрәк вакытка калдырылган, аңа башка затлар да ирекле керү мөмкинлеге булган, (ишек, тәрәзә пыяласы, кузовның бүтән элементлары булмау, бикләнмәгән ишекләр, ишекләр бикләү мөмкинлеге булмау сәбәпле), шулай ук билгеләнеше буенча файдалану мөмкинлеге булмау билгеләре булган (бушаган көпчәкләр, тәгәрмәчләр, башка конструктив детальләр булмау һәм башкалар),транспорт чараларын саклау өчен билгеләнмәгән һәм җәяүлеләр узуга, территория җыештыруга, махсус транспорт һәм чүп-чар җыю машиналарының подъездларга һәм чүп контейнерларына илтүенә комачаулаучы һәм (яки) төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозып урнаштырылган уртак файдалану урыннарында (йорт яны территорияләрендә) урнашкан транспорт чарасы;

махсуслаштырылган автостоянка - ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын саклау өчен билгеләнгән махсус җиһазландырылган һәм саклана торган мәйданчык;

махсуслаштырылган оешма - транспорт чараларын махсус автостоянкага күчерүне гамәлгә ашыручы оешма.

## III. Ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчереп йөртү, саклау, утильләштерү тәртибе

3. Ташланган, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау эшләрен Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Кәчи җирлегенең башкарма комитеты (алга таба - вәкаләтле орган) башкара.

4. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи җирлеге территориясендә ташландык яисә хуҗасыз дип билгеләнгән транспорт чараларын ачыклау вәкаләтле орган тарафыннан, шул исәптән вәкаләтле органга гражданнар, оешмалар мөрәҗәгатьләре, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 10 августындагы "Халык контроле" дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында гражданнарның, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының электрон хезмәттәшлеге турында" 676 номерлы карары нигезендә керә торган мөрәҗәгатьләр (гаризалар) нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Ташланган яисә хуҗасыз дип уйланыла торган транспорт чараларын исәпкә алу вәкаләтле орган тарафыннан ташланган, хуҗасыз транспорт чараларын исәпкә алу журналында (алга таба - исәпкә алу журналы) башкарыла

Исәпләү журналының рәвеше Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Кәчи җирлеге башкарма комитетының карары белән раслана.

Ташланган яки хуҗасыз дип табылган транспорт чарасын ачыклау факты әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә ачыкланган көнне исәпкә алу журналында теркәлә.

6. Әгәр өзекләндерү кагыйдәләрен бозып урнаштырылган, ташланган яисә хуҗасыз транспорт чарасы ачыкланганнан соң 6 ай узгач, вәкаләтле орган транспорт чарасын расланган форма буенча тикшерү акты төзеп, транспорт чарасын комиссион тикшерүне тәэмин итә (3 нче кушымта).

7. Ташланган яисә хуҗасыз транспорт чараларын тикшерү комиссиясе (алга таба - Комиссия) составы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи җирлеге башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

Комиссия составына Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының тиешле муниципаль берәмлек территориясендә бурычларын һәм функцияләрен гамәлгә ашыручы район (районара) дәрәҗәсендәге

территориаль органы (алга таба - эчке эшләр органнары бүлекчәсе) вәкилләре килештереп кертелергә мөмкин.

8. Транспорт чарасын тикшерү актында ташланган яисә хуҗасыз дип билгеләнгән транспорт чарасының төгәл тасвирламасы, түбәндәге мәгълүматны күрсәтеп, булырга тиеш:

марка, модель, кузов төсе һәм шәхси үзенчәлекләре (алар булганда);

дәүләт теркәү билгесе (булган очракта);

идентификация номеры (VIN) (булган һәм керү мөмкинлеге булган очракта);

милекче (транспорт чарасы хуҗасы билгеле булган очракта);

урнашу урыны (урнашу схемасы кушымтасы белән);

тышкы халәт.

Транспорт чарасы белән составта хәрәкәт итү өчен билгеләнгән прицеплар, ярымприцеплар һәм башка җайланмалар өчен тиешле мәгълүмат әлеге төр транспорт чаралары үзенчәлекләрен исәпкә алып күрсәтелә.

Транспорт чарасын тикшерү актында шулай ук механик зарарланулар (бөкләнүләр, тырналган урыннар, тишекләр, өзелүләр һ.б.), тәгәрмәчләрнен, пыялаларның, ишекләрнен, капотның, багажник капкачларынын, тышкы көзгеләрнен, калпакларнын, фар, яктылык приборларының плафоннарынын, тышкы антенналарнын, радиоаппаратуранын, бензобак бөкеләренен, пыяла чистартучы щеткасының булу - булмавы, буяу торышы (коррозия, буяу эзләре булу, аерым детальләрдә яки кузов элементларында лаклы өслек булмау һ.б.).

Комиссия төзегән тикшерү актына фотоматериаллар кушымта итеп бирелә.

Тикшерү акты комиссия рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

9. вәкаләтле орган вәкиле ташландык, хуҗасыз, юл йөрү, җәяүлеләр үтүгә, территорияне җыештыруга, махсус транспорт һәм чүп-чар җыю машиналарының подъездларга һәм чүп-чар контейнерларына керүенә комачаулаучы һәм (яки) Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Кәчи жирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозып урнаштырылган транспорт чарасын тикшерү актына кул куйган көннән алып 3 эш көне эчендә Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә транспорт чарасын күчерү турындагы таләпне урнаштыра. Транспорт чарасын күчерү өчен транспорт чарасын күчерү таләбендә күрсәтелгән вакыт әлеге таләп урнаштырылган көннән башлап 3 эш көнен тәшкил итә.

Транспорт чарасын күчерү турындагы таләп транспорт чарасында алгы яки ян пыялага, ә алар булмаганда - капот, багажник, ишек, транспорт чарасы кузовының башка элементына беркетү юлы белән(шул ук вакытта күрсәтелгән таләпне уку өчен иркле визуаль керү тәэмин ителергә тиеш, шулай ук аңа атмосфера явым-төшемнәренең тәэсире һәм җилнең очырып китүе исәпкә алынырга тиеш) урнаштырыла. Таләпләрне урнаштыру факты фотосъемка белән теркәлә.

10. Транспорт чарасы хуҗасы транспорт чарасын күчерү турында таләпләр урнаштырылганнан соң 3 эш көне эчендә транспорт чарасын күчерү буенча чаралар күрмәгән яки вәкаләтле органга мөрәҗәгать итмәгән очракта, вәкаләтле орган Эчке эшләр органнары бүлекчәләренә

транспорт чарасы хуҗасы булу яки булмау факты турында мәгълүмат бирү турында мөрәҗәгать җибәрә.

11. Эчке эшләр органнары бүлекчәләре тарафыннан транспорт чарасы милекчесенең булуы турында мәгълүмат бирелгән очракта, вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән сорауга җавап алган көннән алып 3 эш көне эчендә ташландык транспорт чарасы билгеләре булган транспорт чарасы хуҗасын ачыклау чараларын гамәлгә ашыра.

12. Ташландык билгеләре булган транспорт чарасы хуҗасы, транспорт чарасы милекчесе ачыкланганда һәм аның яшәү урыны адресын билгеле булганда вәкаләтле орган транспорт чарасы хуҗасына 2 эш көне эчендә транспорт чарасын әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә ирекле рәвештә күчерү турында почта аша заказ хатында рәсмиләштерелгән хәбәрнамәдә таләп җибәрә

Транспорт чарасын күчерү турындагы таләптә транспорт чарасының җәяүлеләр йөрүенә, территорияне җыештыруга, махсус транспорт һәм чүп җыю машиналарын подъездларга һәм чүп контейнерларына һәм (яисә) таләпләрне бозып урнаштырылган төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрне бозган өчен 3 эш көнен тәшкил итә торган транспорт чарасын ирекле күчерү өчен вакыт күрсәтелә, әгәр транспорт чарасы билгеләнгән срокта ирекле рәвештә күчерелмәсә, ул махсуслаштырылган автостоянкага мәҗбүри күчереләчәк (эвакуацияләнгән) күрсәтелә.

Транспорт чарасын күчерү турындагы таләп махсус автостоянкада транспорт чарасын саклау транспорт чарасын махсуслаштырылган автостоянкага күчергәннән соң 1 елга кадәр гамәлгә ашырылуы, шулай ук махсус автостоянканың урнашуы турында кисәтүдән гыйбарәт булырга тиеш. Күрсәтелгән срок узганнан соң транспорт чарасы хуҗасы үзенең транспорт чарасы белән эш итмәсә, күрсәтелгән гамәл милекченең аңа милек хокукыннан баш тартуы буларак бәяләнә, бу суд тәртибендә транспорт чарасын хуҗасыз дип тану өчен нигез булып тора. Транспорт чарасын күчерү турындагы таләптә шулай ук транспорт чараларын утильләштерүче оешма файдасына транспорт чарасына милек хокукыннан баш тарту мөмкинлеге дә күрсәтелә.

Транспорт чарасын күчерү турындагы таләп шулай ук транспорт чарасы хуҗасына вәкаләтле орган вәкиле тарафыннан шәхсән имза куйдырып тапшырылырга мөмкин.

13. Транспорт чарасын күчерү турындагы таләптә билгеләнгән вакыт дәвамында милекче җәяүлеләр йөрүенә, территорияне җыештыруга, махсус транспорт һәм чүп җыю машиналарын подъездларга һәм чүп контейнерларына һәм (яисә) таләпләрне бозып урнаштырылган транспорт

чарасын күчермәгән очракта, вәкаләтле орган күрсәтелгән срок узуга 3 эш көне эчендә махсуслаштырылган оешмага язма мөрәҗәгать җибәрә.

Транспорт чарасын күчерү (эвакуацияләү) махсуслаштырылган оешма белән килештерелгән срокларда, вәкаләтле орган вәкиле һәм Комиссия әгъзалары барында гамәлгә ашырыла, алар транспорт чарасын тикшерү актының күрсәткечләрен чагыштыралар һәм фотоматериаллар белән расланырга тиешле үзгәрешләрне терки (булган очракта) әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә формада транспорт чарасын кабат тикшерү акты төзиләр.

14. Эчке эшләр органнары бүлекчәсе транспорт чарасының милекчесе турында белешмәләр булмаган очракта, вәкаләтле орган эчке эшләр органнары бүлекчәсенең әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатькә җавап алган көннән алып 3 эш көне эчендә ташландык (хуҗасыз) билгеләре булган транспорт чарасы хуҗасын ачыклау чараларын гамәлгә ашыра.

Әгәр транспорт чарасы хуҗасы аның яшәү урыны адресына билгеләнмәгән яисә билгеле булмаса, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан аларның рәсми хәбәрләрен, муниципаль актларны бастырып чыгару өчен файдаланыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары аша вәкаләтле орган әлеге хәбәр чыккан көннән алып 5 эш көне эчендә транспорт чарасын күчерергә кирәклеге турында транспорт чарасы хуҗасы булырга мөмкин кешегә хәбәр итә, анда әгәр ирекле ул тәртиптә күчермәсә, транспорт чарасын махсуслаштырылган автостоянкага мәҗбүри күчерү (эвакуацияләү) турында кисәтү булырга тиеш.

Мөрәҗәгатьтә транспорт чарасын махсуслаштырылган автостоянкада саклау транспорт чарасын махсуслаштырылган автостоянкага күчергән көннән алып 1 ел срок белән гамәлгә ашырылуы турында кисәтү булырга тиеш, аның дәвамында транспорт чарасы хуҗасы аны билгеләнгән тәртиптә алырга мөмкин. Күрсәтелгән срок узганнан соң транспорт чарасы хуҗасы үзенең транспорт чарасы белән эш итмәсә, күрсәтелгән гамәл транспорт чарасын хуҗасыз дип тану өчен суд тәртибендә нигез булып тора. Мөрәҗәгатьтә шулай ук, вәкаләтле органның контактлы телефоннарын күрсәтеп, транспорт чараларын утильләштерүне гамәлгә ашыручы оешма файдасына транспорт чарасына милек хокукыннан баш тарту мөмкинлеге күрсәтелә.

Билгеләнгән срокта милекче җәяүлеләр узуга, территорияне җыештыруга, махсус транспорт һәм чүп-чар җыю машиналарының подъездларга һәм чүп-чар контейнерларына йөртүгә комачаулаучы һәм (яки) төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозып урнаштырылган

транспорт чарасын күчермәсә, вәкаләтле орган транспорт чарасын махсуслаштырылган автостоянкага чыгаруны башкара торган махсус оешманың язма гаризасын җибәрә.

Транспорт чарасын күчерү (эвакуацияләү) махсуслаштырылган оешма белән килештерелгән срокларда, вәкаләтле орган вәкиле һәм Комиссия әгъзалары катнашында гамәлгә ашырыла, алар транспорт чарасын тикшерү актының күрсәткечләрен чагыштыралар һәм фотоматериаллар белән расланырга тиешле үзгәрешләрне (алар булган очракта) терки, әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә формасы буенча транспорт чарасын кабат тикшерү акты төзи.

15. Махсуслаштырылган автостоянкадан транспорт чарасы милекчегә яки аның билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән вәкиленә бары тик шушы транспорт чарасына милек хокукын раслаучы документлар булганда гына тапшырыла.

16. Транспорт чарасын махсуслаштырылган автостоянкага күчергән көннән алып 1 ел узгач, әгәр милекче яисә мөмкин булган милекче үзенең транспорт чарасы белән эш итү буенча гамәлләр кылмаса, вәкаләтле орган, транспорт чарасын ташландык дип тану максатларында, законнарда билгеләнгән тәртиптә судка мөрәҗәгать итә.

17. Транспорт чарасын хуҗасыз дип тану турында суд карары үз көченә кергән көннән алып 3 эш көне эчендә тиешле муниципаль берәмлек өчен милек хокукын тану турындагы карар әлеге транспорт чарасы белән эш итү турындагы карар закон нигезендә кабул ителә.

18. Ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, күчерү, саклау һәм утильләштерүне оештыруга чыгымнарны финанслау тиешле авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи жирлеге башкарма комитетының 2014 елның 28 феврале 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи жирлеге территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен тәртибенә 1 нче кушымта

Транспорт чарасы хуҗасына
марка, модель
______________________
дәүләт теркәве
билгесе
______________________

**Транспорт чарасын күчерү турында таләп**

Тубән Кәчи җирлеге муниципаль берәмлеге, Ташбилге авылы торак пункты

Сезгә, Сез ия булган транспорт чарасы ташландык транспорт чарасы билгеләренә җавап бирә һәм җәяүлеләр үтүгә, территорияне җыештыруга, махсус транспорт һәм чүп җыю машиналары узуга косаулый һәм (яисә) Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясен төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозып урнаштырылган, дип хәбәр итәм.

Әгәр Сезнең транспорт чарасы 20____ елның ________________________ кадәр күчерелмәсә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи жирлеге башкарма комитетынын 2014 елның 28 феврале 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи жирлеге территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен тәртибе нигезендә ______________________________________________ адресы буенча урнашкан махсуслаштырылган автостоянкага транспорт чарасын эвакуацияләү (күчерү) буенча чара күреләчәк.
(муниципаль норматив хокукый акт реквизитлары күрсәтелә)

Сезгә транспорт чарасын күчерү чараларын күрергә яки шәхсән __________________________________________мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итәм. (вәкаләтле органның исеме күрсәтелә)

Белешмәләр өчен телефоннар: ______________________________.

Вәкаләтле орган житәкчесе: __________________
(имза)

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи жирлеге башкарма комитетының 2014 елның 28 феврале 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районынын Тубән Кәчи жирлеге территориясендә ташландык, хужасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен тәртибенә 2 нче кушымта

______________________________
______________________
адресы буенча теркәлгән
______________________________
______________________
гражданга

**Транспорт чарасын күчерү турында таләп**

Тубән Кәчи жирлеге муниципаль берәмлеге, Ташбилге авылы торак пункты

Хөрмәтле ____________________________ !

Сезнең милек хокукында транспорт чарасы бар:

Марка, ТС моделе ________________________________________;

Идентификацион номер (VIN) ________________________________;

ТС җитештерү елы ________________; ТС төзүче оешма (ил) _____________; двигатель № _______________, шасси (рама) ______________________; кузов (кабина, прицеп) ______________; кузов (кабина, прицеп) _______________; ТСны теркәү турындагы таныклык (серия, №______, дәүләт теркәлү билгесе, теркәлү датасы __________________, бирелгән (адресы) ____________________________________________________________

Күрсәтелгән транспорт чарасы ташланган, хужасыз билгеләренә ия: ____________________________________________________________________
___. (билгеләрне күрсәтергә)

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи жирлеге башкарма комитетының 2014 елның 28 феврале 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи жирлеге территориясендә ташландык, хужасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибе нигезендә (муниципаль норматив хокукый акт реквизитлары күрсәтелә)

Сезгә хәрәкәткә, җәяүлеләр үтүгә, территорияне җыештыруга, махсус транспорт һәм чүп җыю машиналарының подъездларга һәм чүп контейнерларына керүшә комачаулаучы һәм (яисә) жирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозып урнаштырылган транспорт чарасын

______________________________________________________

(муниципаль норматив хокукый акт реквизитлары күрсәтелә)

________________________________________ махсуслаштырылган автостоянкага транспорт чарасын эвакуацияләүне (күчерү)__________________ кадәр күчерергә тәкъдим итәм

Әгәр дә Сез ихтыярый рәвештә транспорт чарасын күчермәсәгез, ул мәҗбүри рәвештә 20____ елның _______________ ______сәгать _________ минутта

______________________________________________________

______________________адресы урнашкан махсус автостоянкага эвакуацияләнәчәк.

Сез мөстәкыйль рәвештә махсуслаштырылган автостоянкадан транспорт чарасын алырга тиеш. Махсуслаштырылган автостоянкадан транспорт чарасын алмасагыз, сезнең транспорт чарасын саклау бер елга кадәр башкарыла. Транспорт чарасын махсуслаштырылган автостоянкага күчергәннән соң бер ел узгач, әгәр дә сез махсус автостоянкадан транспорт чарасын алмасагыз, күрсәтелгән гамьсезлек Сезнең аңа милек хокукыннан баш тартуыгыз буларак бәяләнәчәк, бу транспорт чарасын ташланган, хужасыз дип тану өчен нигез булып тора.

Сезнең Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районынын Тубән Кәчи жирлеге территориясендә транспорт чараларын утильләштерүне гамәлгә ашыручы оешма файдасына транспорт чарасына милек хокукыннан баш тартырга хокукыгыз бар.

Моның өчен ______________________________адресы буенча урнашкан_____________________________ мөрәҗәгать итәргә кирәк

(вәкаләтле органның исеме күрсәтелә)

Вәкаләтле орган житәкчесе ______________ __________________

(имза) Ф.И.О.

Тәкъдим белән таныштым

_____________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)

Дата _________________.

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи жирлеге башкарма комитетының 2014 елның 28 феврале 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Тубән Кәчи жирлеге территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен тәртибенә 3 нче кушымта

**Транспорт чарасын тикшерүнең__________№ АКТЫ**

20___ ел "_____" _____________ _____ сәгать _______ минут

_______________________________________________________________
(төзү урыны)

Комиссия составында: комиссия рәисе ______________________________
(вазыйфасы, Ф.И.О.)

һәм комиссия әгъзалары ______________________________

_______________________________________________________________
(комиссия әгъзалары Ф.И.О., вазыйфалары)

_______________________________________________________________

транспорт чарасы ________________________________________
(марка, транспорт чарасы моделе, дәүләт теркәү билгесе, идентификация номеры (VIN), _____________________________________________
төс, кузов номеры, двигатель, шасси һ.б.)

ташландык билгеләре бар, шул сәбәпле____________________________________

_______________________________________________________________
___
(транспорт чарасының торышы, ташландык мөлкәткә кертү билгеләре)

Кушымталар: _____________________________________________

Акт ______ нөсхәдә төзелгән.

Комиссия рәисе: ___________________ ________________ _______________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

Комиссия әгъзалары:_______________ ________________ _______________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

___________________ ________________ _______________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

___________________ ________________ _______________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи жирлеге башкарма комитетының 2014 елның 28 феврале 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Кәчи жирлеге территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен тәртибенә 4 нче кушымта

**Транспорт чарасын тикшерүнең_________№ АКТЫ**

20___ ел "_____" ____________ _____ сәгать _______ минут

______________________________________________________________

(төзү урыны)

Комиссия составында: комиссия рәисе ______________________________

(вазыйфасы, Ф.И.О.)

һәм комиссия әгъзалары

____________________________________________

(комиссия әгъзалары Ф.И.О., вазыйфалары)

______________________________________________________________

катнашында (Транспорт чарасын караган вакытта шунда булган башка затларның вазыйфасы һәм Ф.И.О.)

______________________________________________________________

транспорт чарасы _____________________________________

______________________________________________________________

(марка, транспорт чарасы моделе, дәүләт теркәү билгесе, идентификация номеры (VIN),

______________________________________________________________

төс, кузов номеры, двигатель, шасси һ.б.)

____________________________________________________милек хокукында

(Ф.И.О. Транспорт чарасы милекчесе,ачыкланган очракта)

транспорт чарасының ташландык билгеләре бар, бу тикшерелгән транспорт чарасы "____________ елның "______"____________________ _______№ акты тарафыннан, шулай ук әлеге Акт тарафыннан рәсмиләштерелгән тикшерү нәтиҗәләре белән раслана, тикшерелгән транспорт чарасы

______________________________________________________________

(транспорт чарасының халәте, шул исәптән аны ташландык дип кертү билгеләре)

______________________________________________________________,

шуңа бәйле рәвештә комиссия Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы ________________________________ авыл жирлеге территориясен төзекләндерүнең кагыйдәләре таләпләрен бозып урнаштырылган подъездларга һәм чүп-чар контейнерларына, махсус транспортка һәм чүп

җыю машиналарына һәм юлга комачаулый торган транспорт чарасын эвакуацияләү (күчерү) турында карар кабул итә.

______________________________________________

(җирле үзидарә органының төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турындагы карары реквизитлары)

түбәндәге адрес буенча урнаштырылган махсус автостоянкага: ______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

Кушымталар:

1. Фототаблица - ______ фото, ________ биттә.
2. ______________
3. ______________

Акт җирле үзидарәнең вәкаләтле органында саклана торган берданбер нөсхәдә төзелгән.

Комиссия рәисе: ________________ ________________ ________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

Комиссия әгъзалары:____________ ________________ ________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

____________ ________________ ________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

____________ ________________ ________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

Транспорт чарасын тикшергәндә шунда булган башка затлар:

________________ ________________ ________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

________________ ________________ ________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

________________ ________________ ________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)